БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

8 ноябрь 2021 ел № 80

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген 2 нче кушымта нигезендә;

муниципаль торак контроленең төп күрсәткечләрен һәм аларның максатчан күрсәткечләрен, муниципаль торак контроле өчен индикатив күрсәткечләрне 3 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2021 елның 8 ноябрендәге
80 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроль турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге НигезләмәТатарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен (алга таба – муниципаль торак контроле) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль контроль предметы булып юридик затларның, шәхси эшкуарларның һәм гражданнарның (алга таба – контрольдә торучы затларның) торак законнары, энергияне саклау турында һәм муниципаль торак фондына карата энергетик нәтиҗәлелекне күтәрү турында законнарда билгеләнгән түбәндәге мәҗбури таләпләрне үтәү тора:

1) муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аның сакланышына, шул исәптән торак биналарга, алардан файдалануга һәм аларны карап тотуга, күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренең гомуми мөлкәтеннән файдалануга һәм аны карап тотуга, күпфатирлы йортта торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү тәртибенә, күпфатирлы йортта биналарны яңадан планлаштыру һәм (яки) үзгәртеп кору тәртибенә карата таләпләр;

2) капиталь ремонт фондларын формалаштыруга карата таләпләр;

3) күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы, хезмәт күрсәтүче һәм (яки) күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкару буенча хезмәтләр күрсәтүче юридик затларны, шәхси эшкуарларны булдыруга һәм аларның эшчәнлегенә карата таләпләр;

4) күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы биналарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә карата таләпләр;

5) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешле булмаган сыйфатта һәм (яки) билгеләнгән озынлыктан артып киткән тәнәфесләр белән хезмәтләр күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта, торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләре;

6) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләре һәм торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләре;

7) күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы биналарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү, аны туктатып тору һәм күрсәтәне чикләү кагыйдәләре;

8) энергетик нәтиҗәлелек һәм күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы биналарның энергия ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләре;

9) ресурс белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген башкаручы затлар тарафыннан системада мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләр;

10) күпфатирлы йортларда инвалидлар өчен биналардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр;

11) социаль файдаланудагы наемга алынган йортларда торак урыннары бирүгә карата таләпләр.

1.3. Муниципаль торак контроле Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты (алга таба - Контроль орган) тарафыннан башкарыла.

1.4. Башкарма комитетның муниципаль торак контролен тормышка ашырырга вәкаләтле вазыйфаи заты булып Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы (алга таба – инспектор) тора.

Күрсәтелгән контроль органның вазыйфаи заты вазыйфаи бурычларына аларның вазыйфаи инструкциясе нигезендә муниципаль торак контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру керә.

Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи зат муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 248-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм башка федераль законнар нигезендә хокукларга, бурычларга ия һәм аның нигезендә җавап тота.

Контроль органының контроль чараны үткәрү турында карар кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары булып Контроль орган җитәкчесе, җитәкче урынбасары (алга таба – Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затлары) тора.

1.5. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга, профилактик чаралар, контроль чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә карата Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

1.6. Муниципаль торак контроле объектлары булып түбәндәгеләр тора:

1) алар кысаларында мәҗбүри таләпләр, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктының 1 – 11 пунктчаларында күрсәтелгән эшчәнлекне, гамәл кылуны (гамәл кылмауны) башкаручы контрольдә торучы затларга карата куела торган таләпләр үтәлергә тиешле контрольдә торучы затларның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы);

2) аларга карата әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктының 1 – 11 пунктчаларында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куела торган контрольдә торучы затларның эшчәнлек нәтиҗәләре, шул исәптән продукция (товарлар), эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр;

3) аларга карата әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы 1 – 11 пунктчаларында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куела торган муниципаль торак фондының торак урыннары, муниципаль торак фондының торак урыннары булган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәт һәм башка объектлар.

1.7. Контроль объектларны исәпкә алу түбәндәгеләрне булдыру юлы белән башкарыла:

контроль чараларның бердәм реестрын;

судка кадәр шикаять бирү мәгълүмат системасын (дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмче системаларын);

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән башка дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларын.

1.8. Гражданнар тарафыннан кулланыла торган торак урыннарына карата муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда, планлы тикшерү чаралары үткәрелми .

## II. Зарар (зыян) китерүнең куркыныч (риск) категориясе[1]

2.1. Муниципаль торак контроль профилактик чараларны һәм контроль чараларны сайлап алуны, аларның эчтәлеген (шул исәптән тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрнең күләме), интенсивлыгын һәм нәтиҗәләрен билгели торган зарар (зыян) китерү куркынычы белән идарә итү нигезендә гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта Контроль орган даими нигездә зарар (зыян) китерү куркынычын бәяләү һәм идарә итү өчен файдаланыла торган белешмәләргә мониторинг ясый (җыю, эшкәртү, анализ һәм исәпкә алу).

2.2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, зарар (зыян) китерү куркынычы белән идарә итү максатларында контроль объектлары түбәндәге зарар (зыян) китерү куркынычы категорияләренең (алга таба – куркыныч категориясе)[2] берсенә кертелә:

югары дәрәҗәдәге куркыныч;

урта дәрәҗәдәге куркыныч;

җиңелчә дәрәҗәдәге куркыныч;

түбән дәрәҗәдәге куркыныч.

2.3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү критерийлары әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы белән билгеләнгән.

---

[1] Нигезлзмә белән әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган муниципаль контрольнең әлеге төрен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләр турында Федераль законда башкача билгеләнмәгән булса, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда рисклар белән идарә итү һәм бәяләү системасы кулланылмый дип билгеләнергә мөмкин. Бу очракта планлы контроль чаралар һәм планнан тыш контроль чаралар 248-ФЗ номерлы Федераль законның 61 һәм 66 статьяларында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә (248-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 7 өлеше).

[2] Куркыныч категорияләре исемлеге үрнәк формасында һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясын исәпкә алып, мөстәкыйль билгеләнә.

2.4. Контроль объектын куркынычның бер категориясенә кенртү Контроль органы тарафыннан аның характеристикаларын расланган куркыныч критерийлары белән чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторы булып контроль объекты параметрларыннан туры килү яисә алардан тайпылу тора, алар үзләре мәҗбүри таләпләрне бозмый, әмма югары ихтималлылык дәрәҗәсе белән әлеге бозулар булуны һәм закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычы булуын раслый.

2.5. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге Совет карары белән раслана.

2.6. Контроль объекты билгеле бер куркыныч категориясенә кертелмәгән очракта, ул түбән дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә кертелгән дип санала.

2.7. Контроль орган контроль объектның куркынычның башка категориясе критерийларына туры килүе турында яисә куркыныч критерийларын үзгәртү турында мәгълүмат кергән көннән биш эш көне эчендә контроль объектның куркыныч категориясен үзгәртү турында карар кабул итә.

## III. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда үткәрелә торган профилактик чаралар төрләре

2.5. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырылганда Контроль орган түбәндәге профилактик чараларны[3] үткәрә:

1) мәгълүмат бирү;
2) хокук куллану практикасын гомумиләштерү;
3) кисәтүләр игълан итү;
4) консультация бирү;
5) профилактик визит.

### 3.1. Мәҗбүри таләпләрне үтәү һәм хокук куллану практикасын гомумиләштерү мәсьәләләре буенча контрольдә торучы затларга һәм башка кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1.1. Контроль орган контрольдә торучы затларга һәм башка кызыксынган затларга мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирүне «Интернет» челтәрендә рәсми сайтта (алга таба - рәсми сайтта), массакүләм мәгълүмат чараларында, дәүләт мәгълүмат

---

[3] Профилактик чаралар исемлеге үрнәк формада һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясын исәпкә алып, мөстәкыйль билгеләнә, шул ук вакытта мәгълүмат бирү һәм консультация бирү мәҗбүри.

248-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 6 пунктлары нигезендә Контроль орган, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән профилактик чаралардан тыш, намуслылыкны стимуллаштыру һәм үз-үзен тикшерү чаралары кебек профилактик чаралар үткәрергә мөмкин дип билгеләнде (248-ФЗ номерлы Федераль законның 48 һәм 51 статьялары).

системаларында контрольдә торучы затларның шәхси кабинетларында (алар булганда) һәм башка формаларда түбәндәге белешмәләрне урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны җайга салучы норматив хокукый актлар текстлары;

2) муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр турында, аларның үз көченә керү вакытлары һәм тәртибе турында белешмәләр;

3) аларның үтәлешен бәяләү контроль предметы булып торган мәҗбүри таләпләрне, шулай ук мәҗбүри таләпләрне бозганда кулланыла торган җаваплылык чаралары турында мәгълүматны үз эченә алган актларның структур берәмлекләрен күрсәтеп, гамәлдә булган редакциядәге текстлар белән норматив хокукый актлар исемлеге;

4) үз-үзеңне тикшерү өчен аларны куллануны рөхсәт итә торган форматта расланган тикшерү битләре;

5) мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча җитәкчелек;

6) мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге, контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү тәртибе;

7) куркыныч категориясен күрсәтеп, ел саен контроль чаралар планын формалаштыру кысаларында исәпкә алына торган контроль объектлар исемлеге;

8) зарар китерү куркынычларын профилактикалау программасы һәм Контроль органы тарафыннан планлы контроль чаралар үткәрү планы (мондый чаралар үткәрелгәндә);

9) Контроль орган тарафыннан контрольдә торучы заттан соратып алына торган белешмәләрнең тулы исемлеге;

10) мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча консультацияләр алу ысуллары турында белешмәләр;

11) Контроль орган тарафыннан контрольдә торучы затларның намуслылыгын стимуллаштыру чараларын куллану турында белешмәләр;

12) Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять бирү тәртибе турында белешмәләр;

13) контроль органның хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган докладлар;

14) муниципаль контроль турында докладлар;

15) үз-үзеңне тикшерү ысуллары һәм процедурасы турында мәгълүмат (әгәр ул булса), шул исәптән үз-үзеңне тикшерү уздыру һәм мәҗбүри таләпләрне үтәү декларациясен әзерләү буенча методик тәкъдимнәр һәм контрольдә торучы затлар тарафыннан бирелгән мәҗбүри таләпләрне үтәү декларацияләре турында мәгълүмат;

16) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль

хокукый актларда һәм (яисә) зарар китерү куркынычларын профилактикалау программаларында каралган башка белешмәләр.

### 3.2. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү

3.2.1. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү Контроль орган тарафыннан елга 1 тапкыр үткәрелә һәм түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

1) Контроль орган һәм аның вазыйфаи затлары тарафыннан муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен, мәҗбүри таләпләрне куллануга бертөрле карашларны тәэмин итү;

2) бер типтагы мәҗбүри таләпләрне бозуларны, күрсәтелгән бозулар барлыкка килүгә ярдәм итүче сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау;

3) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү очракларын анализлау, зарар (зыян) китерүнең чыганакларын һәм куркыныч (риск) факторларын ачыклау;

4) мәҗбүри таләпләрне актуальләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

5) дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында, муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнарына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү.

3.2.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында торак контролендә тотуны гамәлгә ашыруның хокук куллану практикасын гомумиләштерү Контроль орган тарафыннан үткәрелгән контроль чаралар һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүматларны җыю һәм анализлау ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

3.2.3 Хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча, Контроль орган хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган доклад әзерли.

3.2.4. Хокук куллану практикасы турында доклад карар белән раслана һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында хисап елыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча урнаштырыла.

### 3.3. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү

3.3.1. Мәҗбүри таләпләрне бозу әзерләнү яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр булган очракта һәм (яисә) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүе яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычы тудыруы турында расланган белешмәләр булмаганда, Контроль орган контрольдә торучы затка мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә тәкъдим итә.

3.3.2. Кисәтү «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типлаштырылган формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы белән расланган форма буенча төзелә.

3.3.3. Контрольдә торучы зат кисәтү алган көннән соң ун эш көне[4] эчендә Контроль органга кисәтүгә карата кире кагу белдерергә хокуклы.

3.3.4. Кире кагуда түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) кире кагу җибәрелә торган Контроль орган исеме;

2) юридик затның исеме, шәхси эшкуарның яки гражданның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы –булганда), шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), контрольдә торучы затка җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) салым түләүченең - юридик затның, шәхси эшкуарның идентификация номеры,

4) паспортның яки гражданның шәхесен раслый торган башка документның сериясе һәм номеры;

5) кисәтү датасы һәм номеры;

6) алар нигезендә контрольдә торучы зат игълан ителгән кисәтүләр белән риза булмаган дәлилләр;

7) контрольдә торучы зат тарафыннан кисәтү алу датасы;

8) шәхси имза һәм дата.

3.3.5. Контроль органга кире кагулар контрольдә торучы зат тарафыннан басма чыганакта почта аша яисә 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда, гади электрон имза яисә көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә Контроль органның кисәтүдә күрсәтелгән электрон почта адресына яисә кисәтүдә күрсәтелгән башка ысуллар белән җибәрелә.

3.3.6. Кирәк булган очракта, контрольдә торучы зат, үз дәлилләрен раслап, кире кагуга тиешле документлар яки аларның расланган күчермәләрен беркетә.

3.3.7. Контроль орган аны алганнан соң унбиш эш көне[5] эчендә кисәтүгә карата кире кагуны карый.

3.3.8. Кире кагуны карау нәтиҗәләре буенча Контроль орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) игълан ителгән кисәтүне гамәлдән чыгару формасында кире кагуны канәгатьләндерә;

2) баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, кире кагуны канәгатьләндерүдән баш тарта.

3.3.9. Контроль орган кисәтүгә карата кире кагуны караган көннән алып биш эш көненнән[5] дә соңга калмыйча контрольдә торучы затка кире кагуны тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

---

[4] Тәкъдим ителгән вакыт, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы башка вакыт билгеләргә хокуклы.

[5] Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

3.3.10. Шул ук нигезләр буенча кире кагуны кабат җибәрү рөхсәт ителми.

3.3.11. Контроль орган мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләрне исәпкә ала һәм тиешле мәгълүматларны башка профилактик чаралар һәм контроль чаралар үткәрү өчен куллана.

## 3.4. Консультация бирү

3.4.1. Контрольдә ротучы затларга һәм аларның вәкилләренә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле түбәндәге мәсьәләләр буенча консультация бирү гамәлгә ашырыла:

1) контроль чаралар үткәрү тәртибе;

2) контроль чаралар үткәрү периодлылыгы;

3) контроль чаралар нәтиҗәләре буенча карарлар кабул итү тәртибе;

4) Контроль орган карарларына шикаять бирү тәртибе.

3.4.2. Инспекторлар контрольдә торучы затларга һәм аларның вәкилләренә түбәндәгечә консультацияләр бирә:

1) телефон буенча телдән аңлатмалар рәвешендә, видео-конференц-элемтә аша, шәхси кабул итүдә яисә профилактик чара, контроль чара уздыру барышында;

2) рәсми сайтта бер типтагы мөрәҗәгатьләр (10 нан артык бер типтагы мөрәҗәгать[6]) буенча контроль органның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган язма аңлатма урнаштыру юлы белән.

3.4.3. Инспекторлар тарафыннан шәхси кабул итүдә һәр мөрәҗәгать итүчегә шәхси консультацияләр бирү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш.

Телефон аша сөйләшү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш.

3.4.4. Контроль орган контрольдә торучы затларга һәм аларның вәкилләренә телдән консультация бирү мәсьәләләре буенча язма рәвештә мәгълүмат бирми.

3.4.5. Язма рәвештә консультация бирү Контроль органның вазыйфаи заты тарафыннан түбәндәге очракларда башкарыла:

а) контрольдә торучы зат тарафыннан консультация бирү мәсьәләләре буенча язмача җавап бирү турында язма гарызнамә бирелде;

б) консультацияләр бирү вакыты дәвамында куелган сорауларга җавап бирү мөмкин түгел;

в) куелган сорауларга җавап өстәмә мәгълүмат соратып алуны таләп итә.

3.4.6. Контрольдә торучы зат «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән вакытларда язма җавап бирү турында гарызнамә җибәрергә хокуклы.

3.4.7. Контроль орган үткәрелгән консультацияләр исәбен алып бара.

### 3.5. Профилактик визит

3.5.1. Профилактик визит инспектор тарафыннан контрольдә торучы затның эшчәнлек алып бару урыны буенча профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән үткәрелә.

3.5.2. Инспекторга түбәндәгеләргә карата мәҗбүри профилактик визит үткәрә:

1) күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыруга керешүче контрольдә торучы затларга карата, мондый эшчәнлек башланганнан бирле бер елдан да соңга калмыйча (эшчәнлек башлану турында мәгълүматлар булганда);

2) югары дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата, контроль объектларын әлеге категориягә кертү турында карар кабул ителгән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча.

3.5.3. Профилактик визитлар контрольдә торучы затлар белән килешенеп үткәрелә.

3.5.4. Контроль орган контрольдә торучы затка профилактик визит үткәрү турында аны үткәрү датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр җибәрә.

Контрольдә торучы зат, бу хакта Контроль органга аны үткәрү датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итеп, профилактик визит уздырудан (мәҗбүри профилактик визитны да кертеп) баш тартырга хокуклы.

3.5.5. Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында хәбәрнамә язма рәвештә яисә электрон документ формасында төзелә һәм түбәндәге белешмәләр үз эченә ала:

1) хәбәрнамәне төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) Контроль орган исеме;

3) контрольдә торучы затның тулы исеме;

4) вәкаләтле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

5) мәҗбүри профилактик визитның датасы, вакыты һәм урыны;

6) вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында хәбәрнамә контрольдә торучы зат адресына язмача яки электрон документ формасында җибәрелә.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү вакыты контроль орган тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә һәм бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

3.5.6. Профилактик визит нәтиҗәләре буенча инспектор профилактик визит үткәрү турында акт төзи.

3.5.7. Контроль орган үткәрелгән профилактик визитларның исәбен алып бара.

## IV. Муниципаль контроль кысаларында үткәрелә торган контроль чаралар

### 4.1. Контроль чаралар. Гомуми мәсьәләләр

4.1.1. Муниципаль контроль түбәндәге планлы һәм планнан тыш контроль чараларны[6] үткәрүне оештыру юлы белән Контроль орган тарафыннан гамәлгә ашырыла:

инспекция визиты, документар тикшерү, урынга чыгып тикшерү – контрольдә торучы затлар белән үзара хезмәттәшлектә;

мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, урынга чыгып тикшерү – контрольдә торучы затлар белән хезмәттәшлексез.

4.1.2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контрольдә торучы затлар белән үзара хезмәттәшлек булып түбәндәгеләр тора:

инспектор һәм контрольдә торучы зат яки аның вәкиле арасында очрашулар, телефон аша һәм башка сөйләшүләр (турыдан-туры бәйләнеш);

документлар, башка материаллар соратып алу;

инспекторның контрольдә торучы зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында булуы (инспекторның һәркем уза алырлык җитештерү объектларында булу очракларыннан тыш).

4.1.3. Контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлек иткәндә башкарыла торган контроль чаралар Контроль орган тарафыннан түбәндәге нигезләр буенча үткәрелә:

1) Контроль органда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яисә зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләрнең булу яисә контроль объектның мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары тарафыннан расланган параметрларга туры килүен яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуын ачыклау;

2) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чаралар үткәрү вакытлары җитү;

3) конкрет контрольдә торучы затларга карата контроль чаралар үткәрү турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең йөкләмәсе;

4) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

5) Контроль орган тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында карарны үтәү вакыты чыгу – Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда.

---

[6] Контроль чаралар исемлеге үрнәк формада һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясын исәпкә алып, мөстәкыйль билгеләнә.

Контроль чаралар, Контроль органның эш планындагы биремнәрне дә кертеп, Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затларының биремнәре, шул исәптән федераль закон белән билгеләнгән очракларда инспекторлар тарафыннан үзара хезмәттәшлексез үткәрелә.

4.1.4. Планлы һәм планнан тыш контроль чаралары, контрольдә торучы затлар белән үзара хезмәттәшлексез үткәрелми торган чаралардан тыш, инспектор һәм контроль чараны үткәрүгә җәлеп ителә торган затлар тарафыннан түбәндәге Контроль гамәлләр[7] башкару юлы белән үткәрелә:

карау;

сораштыру;

язма аңлатмалар алу;

документлар сорату;

экспертиза.

4.1.5. Контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан контроль чара, шулай ук документар тикшерү үткәрү өчен, Контроль органның вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган Контроль органы карары кабул ителә, анда түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) карар кабул итү датасы, вакыты һәм урыны;

2) кем тарафыннан карар кабул ителгән;

3) контроль чараны үткәрү нигезләре;

4) контроль төре;

5) контроль чараны үткәрүгә вәкаләтле инспекторның (инспекторларның, шул исәптән инспекторлар төркеме җитәкчесенең), шулай ук контроль чараны үткәрүгә җәлеп ителә торган белгечләрнең, экспертларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (булганда) яки мондый чараны үткәрүгә җәлеп ителә торган эксперт оешмасының исеме;

6) аңа контроль чара үткәрелә торган контроль объект;

7) контрольдә торучы зат тарафыннан эшчәнлек алып бару урыны адресы яисә контроль чара үткәрелә торган башка контроль объектларының урнашу

адресы рейд тикшерүенә карата күрсәтелмәскә мөмкин;

8) контроль чара уздырыла торган контроль объектның мәҗбүри таләпләргә туры килүе өчен җаваплы гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) яисә оешманың исеме, оешма (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) адресы рейд тикшерүенә карата күрсәтелмәскә мөмкин;

9) контроль чараның төре;

10) контроль чара кысаларында башкарыла торган контроль гамәлләр исемлеге;

11) контроль чара предметы;

12) тикшерү битләре, әгәр аларны куллану мәҗбүри булып торса;

13) контроль чара үткәрү датасы, шул исәптән контрольдә торучы зат

[7] Контроль гамәлләр исемлеге үрнәк формада һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясын исәпкә алып, мөстәкыйль билгеләнә.

белән турыдан-туры хезмәттәшлек вакыты (контрольдә торучы зат белән турыдан-туры хезмәттәшлек вакыты өлешендә рейд тикшерүенә карата күрсәтелмәскә мөмкин);

14) граждан, оешма тарафыннан бирелә торган мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләү өчен кирәк булган документлар исемлеге (контроль чара кысаларында контрольдә торуы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләү максатларында документлар бирү каралган очракта);

15) контроль төре турында нигезләмәдә каралган булса, башка белешмәләр.

Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүне уздыруга, урынга чыгып тикшерүне үткәрүгә карата Нигезләмәнең әлеге пунктының беренче абзацында каралган әлеге контроль чараны үткәрү турында карар кабул итү таләп ителми.

4.1.6. Контроль чаралар Контроль органның контроль чараларны үткәрү турында карарында күрсәтелгән инспекторлар тарафыннан үткәрелә.

Кирәк булганда, Контроль органы контроль чараларны үткәрүгә билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән һәм контроль чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертлар, эксперт оешмалары реестрына кертелгән экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

4.1.7. Контроль чара тәмамланганнан соң, инспектор «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типлаштырылган формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы белән расланган форма буенча контроль чараның актын (алга таба - акт) төзи.

Мондый чара үткәрү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланса, актта нинди мәҗбүри таләп бозылуы, аның нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге белән билгеләнүе күрсәтелә.

Ачыкланган бозуларны бетергән очракта, контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тотучы контроль чара тәмамланганнан соң, актта аны бетерү факты күрсәтелә.

4.1.8. Мәҗбүри таләпләрне бозу дәлиле булган документлар, башка материаллар актка теркәлә.

Контроль чара уздырганда тутырылган тикшерү битләре актка беркетелергә тиеш.

4.1.9. Актны рәсмиләштерү, әгәр актны рәсмиләштерүнең башка тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәгән булса, мондый чараны үткәрү көнендә контроль чара үткәрү урыны буенча башкарыла.

4.1.10. Дәүләт, коммерция, хезмәт, закон тарафыннан саклана торган серләрне тәшкил итүче контроль чара нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

4.1.11. Контроль чара актында бәян ителгән фактлар һәм нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, контрольдә торучы зат әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә каралган тәртиптә шикаять җибәрергә хокуклы.

## 4.2. Контроль чаралар нәтиҗәләре буенча Контроль орган тарафыннан күрелә торган чаралар

4.2.1. Контроль органы контроль чара үткәргәндә контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә тәбәндәгеләргә бурычлы:

1) контроль чарасы актын рәсмиләштергәннән соң, контрольдә торучы затка аларны бетерү вакытының тиешле вакытларын, тик алты айдан да артык түгел, (документар тикшерү уздырганда күрсәтмә контрольдә торучы затка, документар тикшерү тәмамланганнан соң, биш эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә) күрсәтеп, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында һәм (яисә) саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүне булдырмау буенча чаралар, шулай ук контроль төре турында федераль законда каралган башка чаралар үткәрү турында күрсәтмә (алга таба - күрсәтмә) бирергә;

2) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүне булдырмау яисә зарар (зыян) китерүне, биналарны, корылмаларны, корылмаларны, бүлмәләрне, транспорт чараларын һәм башка шундый объектларны эксплуатацияләүне (файдалануны) тыю турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать итүгә кадәр җитеп, туктату буенча һәм әгәр контроль чараны үткәргәндә контроль объектына ия булган һәм (яисә) аннан файдалана торган гражданның, оешмаларның эшчәнлеге, алар тарафыннан биналарны, төзелешләрне, корылмаларны, биналарны, җайланмаларны, транспорт чараларын һәм башка шундый объектларны эксплуатацияләү (файдалану) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә турыдан-туры зарар (зыян) китерү куркынычы янаган яисә мондый зарар (зыян) китерелгән очракта, гражданнар, оешмалар игътибарына теләсә нинди мөмкин булган ысул белән закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычы булу турында һәм аны булдырмау ысуллары турында мәгълүмат җиткерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кичекмәстән кабул итәргә;

3) контроль чара барышында җинаять яки административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, тиешле мәгълүматны үз компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрергә;

4) мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, законда саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүне булдырмау буенча чаралар күрергә, күрсәтмәне билгеләнгән вакытка үтәмәгән очракта, әгәр мондый чара законнарда каралган булса, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турында таләп белән судка мөрәҗәгать итүгә кадәр җитеп, аның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

5) мәҗбүри таләпләрне үтәү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалауга

юнәлдерелгән башка чаралар үткәрү буенча рекомендацияләр бирү турында мәсьәләне карарга.

4.2.2. Күрсәтмәнең үтәлү вакыты чykканчы, контрольдә торучы зат мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне раслый торган документларны һәм белешмәләрне беркетеп, күрсәтмәнең үтәлүе турында Контроль органга хәбәр итә.

4.2.3. Контрольдә торучы зат тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә кабул ителгән карарның үтәлү вакыты чыккач, яисә күрсәтелгән вакыт узганчы контрольдә торучы зат күрсәтелгән карар белән билгеләнгән документларны һәм белешмәләрне тапшырганда, яисә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) кысаларында мәгълүмат алынган очракта, Контроль орган карарның үтәлешен тапшырылган документлар һәм белешмәләр, алынган мәгълүмат нигезендә бәяли.

4.2.4. Контрольдә торучы зат тарафыннан күрсәтмәне үтәү очрагында, Контроль орган контрольдә торучы затка күрсәтмәнең үтәлеше турында хәбәрнамә җибәрә.

4.2.5. Контрольдә торучы зат тарафыннан күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр тапшырылмаган булса, яисә алар нигезендә яки мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) кысаларында алынган мәгълүмат нигезендә карарның үтәлеше турында нәтиҗә ясау мөмкин булмаса, Контроль орган әлеге карарның үтәлешен инспекция визиты яки документар тикшерү юлы белән[8] бәяли.

Урынга чыгып тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарның үтәлешенә бәя бирелгән очракта, урынга чыгып тикшерү үткәрергә рөхсәт ителә.

4.2.6. Әлеге Нигезләмәнең 4.2.5 пунктында каралган Контроль чара үткәрү нәтиҗәләре буенча Контроль орган карарның үтәлмәве яки тиешенчә үтәлмәве ачыкланса, ул әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктындагы 1 пунктчасында каралган карарны, аны үтәүнең яңа вакытларын күрсәтеп, яңадан контрольдә торучы затка тапшыра.

Күрсәтмәне билгеләнгән вакытка үтәмәгән очракта, Контроль орган, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турында таләп белән судка мөрәҗәгать итүгә кадәр җитеп, аның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрә.

Контроль орган карарының үтәлеше турында мәгълүмат тулы күләмдә контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрына кертелә.

---

[8] 248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлеше нигезендә әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктындагы 1 пунктчасы нигезендә кабул ителгән карарның үтәлешен бәяләү 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясындагы 2 өлешенең 1-6 пунктларында каралган башка контроль чаралар уздыру юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Бу очракта күрсәтелгән контроль чаралар әлеге Нигезләмәдә каралырга тиеш.

## 4.3. Планлы контроль чаралар[9]

4.3.1. Планлы контроль чаралар чираттагы календарь елына Контроль орган тарафыннан төзелә торган һәм прокуратура органнары белән килештерелергә тиешле планлы тикшерү чаралары планы нигезендә үткәрелә.

4.3.2. Куркынычның аерым категорияләренә кертелгән контроль объектларына карата планлы тикшерү чаралары үткәрү төрләре, периодлылыгы зарар (зыян) китерү куркынычына карап билгеләнә.

4.3.3. Контроль орган түбәндәге планлы тикшерү чараларын[11] үткәрергә мөмкин:

инспекция визиты;

документар тикшерү;

урынга чыгып тикшерү.

Югары дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә керә торган объектларга карата инспекция визиты, документар тикшерү, урынга чыгып тикшерү үткәрелә[10]

Урта дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә керә торган объектларга карата инспекция визиты, документар тикшерү, урынга чыгып тикшерү үткәрелә[11]

Җиңелчә дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә керүче объектларга карата инспекция визиты, документар тикшерү, урынга чыгып тикшерү үткәрелә[11]

4.3.4. Контроль объектларына карата планлы контроль чаралар үткәрү түбәндәге периодлылык белән башкарыла:

югары зур дәрәҗәдәге куркыныч категориясе өчен - 2 елга бер тапкыр.

урта дәрәҗәдәге куркыныч категориясе өчен – 3 елга бер тапкыр.

җиңелчә дәрәҗәдәге куркыныч категориясе өчен – 5 елга бер тапкыр.

Түбән дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектына карата планлы контроль чаралар үткәрелми.

4.3.5. Гражданнар тарафыннан кулланыла торган торак урыннарына карата муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда, планлы контроль чаралар үткәрелми.

## 4.4. Планнан тыш тикшерү чаралары

4.4.1. Планнан тыш контроль чаралар документар һәм урынга чыгып тикшерүләр, инспекция визиты мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, урынга чыгып тикшерү (обследование) рәвешендә үткәрелә.

4.4.2. Планнан тыш контроль чара үткәрү турында карар мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторларын исәпкә алып кабул ителә.

---

[9] Нигезләмәдә контроль төренең планлы контроль чаралар үткәрмичә гамәлгә ашырылуы билгеләнергә мөмкин (248-ФЗ номерлы Федераль законның 61 статьясындагы 2 өлеше).

[10] Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы куркынычның һәр категориясе өчен контроль объектларына карата, түбән дәрәҗәдәге куркыныч категориясеннән тыш, планлы контроль чаралар төрләре билгеләнә (248-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 5 өлешенең 5 пункты, 25 статьясындагы 1 өлеше).

4.4.3. Планнан тыш контроль чаралар, үзара хезмәттәшлексез планнан тыш контроль чаралардан тыш, түбәндәге нигезләр буенча үткәрелә:

1) Контроль органда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яисә зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләр булу яисә контроль объектның мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары тарафыннан расланган параметрларга туры килүе яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуы ачыклану;

2) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чаралар үткәрү вакытлары җитү;

3) конкрет контрольдә торучы затларга карата контроль чаралар үткәрү турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең йөкләмәсе;

4) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

5) мәҗбүри таләпләрне бетерү турында Контроль орган карарын үтәү вакыты чыгу (әлеге Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда);

6) әгәр контроль төре турында федераль законда контроль чараларның тикшерүләр программасы нигезендә үткәрелүе билгеләнсә, тикшерү программасында күрсәтелгән вакыйга булу.

4.4.4. Планнан тыш контроль чара прокуратура органнары белән килештерелгәннән соң гына үткәрелергә мөмкин булса, әлеге чара мондый килешүдән соң үткәрелә.

## 4.5. Документар тикшерү

4.5.1. Документар тикшерү дигәндә Контроль органның урнашу урыны буенча үткәрелә торган һәм контрольдә торучы затларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган документларындагы белешмәләр, шулай ук аларның эшчәнлеген тормышка ашырганда кулланыла торган һәм Контроль органның мәҗбүри таләпләрен һәм карарларын үтәү белән бәйле документлар аның предметы булып торган контроль чара аңлашыла.

4.5.2. Контроль орган карамагында булган документларда булган белешмәләрнең дөреслеге нигезле шик тудырса яки бу белешмәләр контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, Контроль орган контрольдә торучы зат адресына документар тикшерү барышында карап тикшерү өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбен җибәрә.

Әлеге таләп алынганнан соң ун эш көне эчендә контрольдә торучы зат таләпләрдә күрсәтелгән документларны Контроль органга җибәрергә тиеш.

4.5.3. Документар тикшерү үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмаска

тиеш.

Күрсәтелгән вакытка түбәндәге чорлар кертелми:

1) Контроль орган тарафыннан контрольдә торучы затка документар тикшерү барышында карап тикшерү өчен кирәкле документларны тапшыру таләбе җибәрелгән вакыттан алып таләптә күрсәтелгән документларны Контроль органга тапшырганчы кадәр чор;

2) Контроль орган контрольдә торучы затка түбәндәгеләр турында мәгълүмат җибәргәннән соңгы чор:

Контрольдә торучы зат биргән документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыклану турында;

бирелгән документлардагы белешмәләрнең Контроль органда булган документлардагы һәм (яки) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган документлардагы белешмәләргә туры килмәве турында һәм күрсәтелгән аңлатмаларны Контроль органга тапшырганчы, кирәкле аңлатмаларны язма рәвештә тапшыру таләбе.

4.5.4. Документар тикшерү барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:

1) документлар соратып алу;

2) язма аңлатмалар алу;

3) экспертиза.

4.5.5. Контроль чара үткәрү барышында инспектор контрольдә торучы затка контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләүне уздыру өчен кирәкле һәм (яки) әһәмияткә ия булган документларныһәм (яисә) аларның күчермәләрен, шул исәптән фотога төшерү, аудио- һәм видеоязмалар, мәгълүмат базалары, мәгълүматлар банкы материалларын, шулай ук мәгълүмат туплагыч материалларын да тапшыру турында таләп куярга (җибәрергә) хокуклы.

Контрольдә торучы зат документларны тапшыру турында таләптә күрсәтелгән вакыт эчендә соратылган документларны Контроль органга җибәрә яисә кичекмәстән язма формадагы үтенечнамә белән инспекторга, сәбәпләрен һәм контрольдә торучы зат кирәкле документларны кайсы вакытка тапшыра алуын күрсәтеп, документларны тиешле вакытка бирү мөмкинлеге булмавы турында хәбәр итә.

Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма материалларынан, мәгълүмат базаларынан, мәгълүмат банкларынан, шулай ук мәгълүмат туплагычлардан файдалану логин һәм пароль рәвешендә, документар тикшерү уздыру вакытына контроль чаралар үткәрү өчен кирәк булган мәгълүматны карау һәм эзләү хокукы белән бирелә.

4.5.6. Язма аңлатмалар инспектор тарафыннан контрольдә торучы заттан яки аның вәкиленнән, шаһитлардан соратып алынырга мөмкин.

Күрсәтелгән затлар инспекторга тикшерү тәмамланганчы ике[5] эш көненнән дә соңга калмыйча ирекле формада язма аңлатмалар бирә.

Язма аңлатмалар ирекле формада язма документ төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

Инспектор контрольдә торучы затлар булган оешманың вазыйфаи затлары яки хезмәткәрләре, аларның вәкилләре, шаһитлар сүзләреннән үз кулы белән язма аңлатмалар төзергә хокуклы. Бу очракта күрсәтелгән затлар аңлатмалар белән танышалар, кирәк булганда текстны тулыландыралар, инспекторның аларның сүзләреннән дөрес язулары турында тамга ясыйлар һәм аны төзү датасын һәм урынын күрсәтеп, документка имза куялар.

4.5.7. Экспертиза Контроль орган кушуы буенча эксперт яки эксперт оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Экспертиза контрольдә торучы затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча да, шулай ук эксперт яки эксперт оешмасы эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча да башкарылырга мөмкин.

Экспертизаны гамәлгә ашыру вакыты экспертиза төренә бәйле һәм Контроль орган белән эксперт яки эксперт оешмасы арасындагы килешү буенча һәр конкрет очрак өчен аерым билгеләнә.

Экспертиза нәтиҗәләре эксперт бәяләмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.5.8. Актны рәсмиләштерү Контроль органның документар тикшерү узган көнне урнашкан урыны буенча башкарыла.

4.5.9. Акт контрольдә торучы затка 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә документар тикшерү тәмамланганнан соң биш[5] эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

4.5.10. Планнан тыш документар тикшерү прокуратура органнары белән килештермичә генә үткәрелә.

## 4.6. Урынга чыгып тикшерү[11]

4.6.1. Урынга чыгып тикшерү контрольдә торучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) яконтроль объектының урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча үткәрелә.

Урынга чыгып тикшерү дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып, шул исәптән аудио - яки видеоэлемтә ярдәмендә үткәрелергә мөмкин.

4.6.2. Урынга чыгып тикшерү түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракта үткәрелә:

1) Контроль орган карамагында булган яки ул соратып ала торган

---

[5] Тәкъдим ителгән вакыт, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы башка вакыт билгеләргә хокуклы.

[11] 248-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясындагы 4 һәм 9 өлешләре нигезендә контроль төре турында Нигезләмә тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүнең билгеле бер куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата урынга чыгып тикшерүләр үткәрүне чикләүне билгеләргә мөмкин.

Контроль төре турында нигезләмәдә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүнең билгеле бер куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата урынга чыгып тикшерү уздырган вакытта аерым контроль гамәлләрнең кыскартылган күләмендә башкарылуы каралырга мөмкин.

документларда һәм контрольдә торучы затның аңлатмаларында булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген дәлилләп булмаганда

2) урынга чыкмыйча контрольдә торучы затның эшчәнлегенең, гамәлләренең (гамәл кылмавының) һәм (яки) аның карамагындагы һәм (яки) ул файдаланучы контроль объектларының әлеге Нигезләмәнең 4.6.1 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен бәяләп һәм контроль чараларның башка төре кысаларында каралган кирәкле контроль гамәлләр кылып булмый.

4.6.3. Планнан тыш урынга чыгып тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килешү буенча гына түбәндәге нигезләр буенча үткәрелергә мөмкин:

1) контроль органда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яисә зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләр булу яисә контроль объектның мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары тарафыннан расланган параметрларга туры килүе яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуы ачыклану;

2) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чаралар үткәрү вакытлары җитү;

3) конкрет контрольдә торучы затларга карата контроль чаралар үткәрү турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең йөкләмәсе;

4) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

5) Контроль орган тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында карарны үтәү вакыты чыгу (248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда).

6) әгәр контроль төре турында федераль законда контроль чараларның тикшерүләр программасы нигезендә үткәрелүе билгеләнсә, тикшерү программасында күрсәтелгән вакыйга булу;

7) законда саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүнең турыдан-туры янавы турында белешмәләр алганда.

4.6.4. Контроль орган урынга чыгып тикшерүне үткәрү турында карарның күчермәләрен контрольдә торучы затка тикшерү башланганчыга кадәр егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча җибәрү юлы белән, контрольдә торучы затка урынга чыгып тикшерүне үткәрү турында хәбәр итә.

4.6.5. Инспектор урынга чыгып тикшерү уздырганда контрольдә торучы затка (аның вәкиленә) хезмәт таныклыгын, урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карарның күчермәсен күрсәтә, шулай ук Контроль чараларның бердәм реестрындагы хисап номерын хәбәр итә.

4.6.6. Урынга чыгып тикшерүне үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмый.

Бер кече эшкуарлык субъектына карата урынга чыгып тикшерү барышында үзара хезмәттәшлекнең гомуми вакыты кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

4.6.7. Урынга чыгып тикшерү барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге[12]:

1) карау;

2) сораштыру;

3) документлар соратып алу;

4) язма аңлатмалар алу;

5) экспертиза.

4.6.8. Карау инспектор тарафыннан контрольдә торучы зат һәм (яки) аның вәкиле барында, видеоязма кулланып башкарыла.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча карау беркетмәсе төзелә.

4.6.9. Сораштыру дигәндә контрольдә торучы заттан яисә аның вәкиленнән һәм мондый мәгълүмат булган башка затлардан контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләүне уздыру өчен әһәмияткә ия булган телдән мәгълүмат алудан гыйбарәт контроль гамәл аңлашыла.

Сораштыру нәтиҗәләре үзе бәян иткән белешмәләрнең дөреслеген раслаучы сораштырыла торган зат тарафыннан имзаланган сораштыру беркетмәсендә, шулай ук алынган белешмәләр контроль чара өчен зур әһәмияткә ия булган очракта, контроль чара актында теркәлә.

4.6.10. Тикшерү, сораштыру үткәргәндә, мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, инспектор мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү өчен фотога төшерү, аудио - һәм видеоязма, дәлилләрне теркәүнең башка алымнарын кулланырга хокуклы.

Фотога төшерү ярдәмендә мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының һәркайсының икедән дә ким булмаган фоторәсемен ясау белән башкарыла.

Фотога төшерү һәм видеоязмаларны мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү өчен куллану дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4.6.11. Контрольдә торучы зат тарафыннан таләп ителә торган документларны, язма аңлатмаларны тапшыру, экспертиза үткәрү әлеге Нигезләмәнең 4.5.5, 4.5.6 һәм 4.5.7 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.6.12. Урынга чыгып тикшерү тәмамланганнан соң инспектор урынга чыгып тикшерү акты төзи.

Фотога төшерү, аудио-һәм видеоязма үткәрү турында мәгълүмат тикшерү актында чагылдырыла.

Актны дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып, шул исәптән аудио - яки видеоэлемтә аша урынга чыгып тикшерү үткәргән очракта,

[12] Контроль гамәлләр исемлеге үрнәк формада һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясын исәпкә алып, мөстәкыйль билгеләнә.

Нигезләмәнең әлеге пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән нигезләмә кулланылмый.

4.6.13. Урынга чыгып тикшерүне үткәрү, контрольдә торучы затның урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча булмавы сәбәпле, яисә контрольдә торучы зат эшчәнлегенең фактта башкарылмавы сәбәпле, яисә контрольдә торучы затның урынга чыгып тикшерүне үткәрүгә яисә тәмамлауга мөмкинлек бирмәвенә китергән башка гамәлләре (гамәл кылмавы) белән сәбәпле, урынга чыгып тикшерү уздыру мөмкинлеге булмаса, инспектор сәбәпләрен күрсәтеп, урынга чыгып тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзи һәм контрольдә торучы затка Федераль законның 21 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә каралган тәртиптә контроль чаралар үткәрү мөмкинлеге булмау турында хәбәр итә.

Бу очракта инспектор урынга чыгып тикшерүне үткәргәнчегә кадәр теләсә кайсы вакытта, әлеге чор кысаларында контроль гамәлләр кылырга хокуклы.

4.6.14. Контрольдә торучы затлар булган шәхси эшкуар, граждан контроль Контроль органга түбәндәге очракларда контроль чаралар үткәргәндә катнаша алмавы турында мәгълүмат бирергә хокуклы:

1) вакытлыча эшкә сәләтсезлек;

2) судлар, хокук саклау органнары, хәрби комиссариатлар чакыруы (хәбәрнамәләре, повесткалары) буенча килү зарурлыгы;

3) Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексы нигезендә контроль чаралар үткәргәндә булу мөмкинлеген юкка чыгара торган чикләү чараларын сайлау;

4) хезмәт командировкасында булу.

Мәгълүмат кергәндә контроль чаралар үткәрү Контроль орган тарафыннан шәхси эшкуарның һәм гражданның әлеге мөрәҗәгатенә сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерелә.

4.7. Инспекция визиты

4.7.1. Инспекция визиты контрольдә торучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) яки контроль объектының урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча үткәрелә.

Инспекция визиты контрольдә торучы затка һәм җитештерү объекты милекчесенә алдан хәбәр итмичә үткәрелә.

Контрольдә торучы затлар яки аларның вәкилләре инспекторның биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

Инспекция визитын үткәрү вакыты бер урында яки бер җитештерү объектында (территориядә) бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

4.7.2. Инспекция визиты барышында рөхсәт ителгән контроль гамәлләр исемлеге:[13]

[13] Контроль гамәлләр исемлеге үрнәк формада һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 70 статьясын исәпкә алып, мөстәкыйль билгеләнә.

а) карау;

б) сораштыру;

в) язма аңлатмалар алу;

г) мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдә торучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) яки контроль объектының урнашу (эшчәнлек алып бару) урынында булырга тиешле документларны соратып алу.

Инспекция визитын дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып, шул исәптән аудио - яки видеоэлемтә аша үткәрергә рөхсәт ителә.

4.7.3. Планнан тыш инспекция визиты бары тик прокуратура органнары белән килешү буенча гына түбәндәге нигезләр буенча үткәрелергә мөмкин:

1) контроль органда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яисә зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләр булу яисә контроль объектның мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары тарафыннан расланган параметрларга туры килүе яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуы ачыклану;

2) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чаралар үткәрү вакытлары җитү;

3) конкрет контрольдә торучы затларга карата контроль чаралар үткәрү турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең йөкләмәсе;

4) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

5) Контроль орган тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында карарны үтәү вакыты чыгу (248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда).

6) ) әгәр контроль төре турында федераль законда контроль чараларның тикшерүләр программасы нигезендә үткәрелүе билгеләнсә, тикшерү программасында күрсәтелгән вакыйга булу;

7) законда саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүнең турыдан-туры янавы турында белешмәләр алганда.

4.7.9. Әлеге Нигезләмәнең 4.7.2 пунктында каралган контроль гамәлләр әлеге Нигезләмәнең 4.5.5, 4.5.6, 4.6.8-4.6.10 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 4.8. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы)

4.8.1. Контроль орган мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәткәндә (куркынычсызлык мониторингында) Контроль органда булган контроль объектлары турында мәгълүматларны, шул исәптән ведомствоара

мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кергән, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында контрольдә торучы затлар тарафыннан тапшырылган мәгълүматларны, шулай ук «Интернет» челтәреннән мәгълүматларны, башка һәркем файдалана алырлык мәгълүматларны, шулай ук фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган хокук бозуларны теркәүнең автоматик режимында эшләүче техник чараларын кулланып алынган мәгълүматларны җыюны, анализлауны башкара.

4.8.2. Әгәр мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) барышында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яки зарар (зыян) китерү куркынычы барлыкка килү фактлары, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, мәҗбүри таләпләрне бозулар әзерләнү яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр ачыкланса, Контроль орган тарафыннан планнан тыш контроль чара үткәрү турында түбәндәге карарлар кабул ителергә мөмкин:

закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яисә зарар (зыян) китерү куркынычы янау турында белешмәләрнең дөреслеге раслаганда яисә контрольдә торучы затның аларның туры килүе яки алардан тайпылуы, мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының расланган индикаторлары нигезендә контроль чара үткәрү өчен нигез булып торган эшчәнлек параметрлары билгеләнгәндә - контроль чара үткәрү турында дәлилләнгән күрсәтмә;

закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яисә зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләрнең дөреслеге расланмаганда, шулай ук контрольдә торучы затның аларның туры килүе яки алардан тайпылуы, мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының расланган индикаторлары нигезендә контроль чара үткәрү өчен нигез булып торган эшчәнлек параметрларын билгеләп булмаганда - мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүне җибәрү турында дәлилләнгән күрсәтмә;

гражданның шәхесен, оешма вәкиленең вәкаләтләрен раслау мөмкин булмаса, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яки зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләрнең дөрес булмавы ачыкланганда - контроль чара үткәрү өчен нигез булмау турында дәлилләнгән күрсәтмә.

2) кисәтү игълан итү турында карар;

3) Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү турында карар.

4) Федераль законның 90 статьясындагы 3 өлеше нигезендә. контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында беркетелгән карар.

## 4.9. Урынга чыгып тикшерү (обследование)

4.9.1. Урынга чыгып тикшерү контрольдә торучы затлар тарафыннан

мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә.

4.9.2. Урынга чыгып тикшерү оешманың (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерым структур бүлекчәләрнең) урнашкан (эшчәнлек алып бару), гражданның эшчәнлек алып бару урыны, контроль объектының урнашу урыны буенча үткәрелергә мөмкин, шул ук вакытта контрольдә торучы зат белән хезмәттәшлек итү рөхсәт ителми.

Җитештерү объектларында һәркем уза алырлык (чикләнмәгән күләмдә затлар булу өчен ачык) җитештерү объектларында карау (осмотр)[14] уздырылырга мөмкин.

4.9.3. Урынга чыгып тикшерү контрольдә торучы затка мәгълүмат бирмичә үткәрелә.

Бер объектны (бер-берсенә якын урнашкан берничә объектны) урынга чыгып тикшерү уздыру вакыты бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

4.9.4. Урынга чыгып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында каралган карарлар кабул ителә алмый.

## V. Судка кадәр шикаять бирү[15]

5.1. Муниципаль җир контрольне гамәлгә ашыру кысаларында аларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре, алар фикеренчә, турыдан-туры бозылган контрольдә торучы затлар түбәндәгеләргә судка кадәр шикаять бирүгә хокуклы:

1) контроль чаралар үткәрү турында карарлар;

2) контроль чаралар актлары, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр;

3) контроль чаралар кысаларында Контроль органның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына).

5.2. Шикаять контрольдә торучы зат тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталларын кулланып электрон рәвештә Контроль органга тапшырыла.

Граждан шикаять тапшырганда, ул гади электрон имза яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган булырга тиеш. Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

[14] Нигезләмәдә 248-ФЗ номерлы Федераль законның 75 статьясында каралган башка контроль чаралар үткәрү билгеләнергә мөмкин.

[15] Нигезләмәдә, әгәр дә контроль төре турында Федераль законда башкача Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган муниципаль контрольнең әлеге төрен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләрдә билгеләнмәгән булса, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда шикаятьләр бирүнең судка кадәр тәртибе кулланыла алмый дип билгеләнергә мөмкин (248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше).

Шикаятькә беркетелә торган материаллар, шул исәптән фото- һәм видеоматериаллар контрольдә торучы зат тарафыннан электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаять, контрольдә торучы зат тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланмыйча, дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып басма чыганакта тапшырыла.

5.3. Контроль органның карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Контроль орган җитәкчесе[16] тарафыннан карала.

Контроль орган җитәкчесенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Балтач муниципаль районы башлыгы тарафыннан карала.

5.4. Шикаять контрольдә торучы зат үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән соң утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Контроль орган күрсәтмәсенә шикаять контрольдә торучы зат тарафыннан күрсәтмә алынганнан соң ун эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

5.5. Шикаять бирү вакытының нигезле сәбәбе булган очракта, бу вакыт контрольдә торучы зат үтенечнамәсе буенча Контроль орган тарафыннан торгызылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шикаятьне кабат шул ук нигезләр буенча җибәрү рөхсәт ителми.

5.7. Шикаятьтә Контроль органның шикаять белдерелә торган карарын үтәүне туктатып тору турында үтенечнамә булырга мөмкин.

5.8. Шикаятьне теркәгәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча Контроль органның җитәкчесе түбәндәгеләр турында карар кабул итә:

1) Контроль органның шикаять бирелә торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органның шикаять бирелә торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тарту турында;

Кабул ителгән карар турында мәгълүмат шикаять биргән контрольдә торучы затка, карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә җибәрелә.

5.9. Шикаять үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

1) Контроль органның исеме, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), аларга шикаять бирелә торган карар һәм (яки) гамәлләр (гамәл кылмау);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны (эшчәнлек алып бару урыны) турында белешмәләр яисә мөрәҗәгать

---

[16] Нигезләмәдә Контроль органда аның вазыйфаи затларыннан торган шикаятьләрне карау өчен коллегиаль орган (коллегиаль органнар) төзү каралырга мөмкин (248-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 3 өлеше).

итүче оешманың исеме, әлеге оешманың урнашу урыны турында белешмәләр,
яисә ышанычнамә реквизитлары, ышанычнамә буенча шикаять бирүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), шикаятьне карау вакытында үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча карарны алуның теләгән ысулы;

3) шикаять биргән контрольдә торучы затның хокукларын бозуга китерә яисә китерә ала торган Контроль органның шикаять бирелә торган карары һәм (яки) аның вазыйфаи затының гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче алар нигезендә Контроль орган карары һәм (яки) вазыйфаи затның гамәлләре (гамәл кылмавы) белән риза булмаган нигезләр һәм дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин;

5) шикаять биргән контрольдә торучы зат таләпләре;

6) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, шикаять бирелә торган Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрында контроль чараның исәп номеры.

5.10. Шикаятьтә әдәпсез яки мәсхәрәле сүзләр, Контроль органның вазыйфаи затларының яки аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булырга тиеш түгел.

5.11. Аңа тиешле хокук бирелгән очракта, шикаять бирү контрольдә торучы затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә башкарылырга мөмкин.

5.12. Контроль орган шикаять алынганнан соң биш эш көне эчендә шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 5.4 пунктында күрсәтелгән шикаять бирү вакыты тәмамланганнан соң бирелгән һәм аны торгызу турында яки шикаять бирүнең үткән вакытын торгызуга үтенечнамәләр юк;

2) шикаять бирүнең үткән вакытын торгызу турында үтенечнамәне канәгатьләндерүдән
баш тартылган;

3) шикаять буенча карар кабул ителгәнче, аны биргән контрольдә торучы заттан шикаятьне кире алу турында гариза кергән;

4) шикаятьтә куелган мәсьәләләр буенча суд карары бар;

5) элек шул ук контрольдә торучы затлар тарафыннан шул ук нигезләр буенча Контроль органга башка шикаять бирелгән;

6) шикаятьтә әдәпсез яки мәсхәрәле сүзләр, Контроль органның вазыйфаи затларының яки аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар бар;

7) элегрәк әлеге контрольдә тотучы затның шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгара торган шул ук мәсьәлә буенча

шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту алынды һәм яңа дәлилләр яисә шартлар китерелми;

8) шикаять тиеш булмаган органга тапшырылган;

9) Россия Федерациясе законнарында Контроль органы карарларына суд тәртибендә шикаять бирү генә каралган.

5.13. Әлеге Нигезләмәнең 5.12 пунктындагы 3-8 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм контроль орган карарларына, вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка шикаять бирү өчен нигез була алмый.

5.14. Шикаятьне караганда Контроль орган, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган контроль эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасын алып бару кагыйдәләре нигезендә, контроль эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасын куллана.

Контроль орган контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә карата судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләрне тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау, дәүләт яисә закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасын кулланмыйча, Контроль орган җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.15 Шикаять Контроль орган җитәкчесе тарафыннан аны теркәгән көннән егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.16. Күрсәтелгән вакыт түбәндәге аерым очракларда егерме эш көненә озайтылырга мөмкин:

1) аның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган вазыйфаи затка карата шикаятьтә күрсәтелгән фактлар буенча хезмәт тикшерүе уздыру;

2) аның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган вазыйфаи затның нигезле сәбәпләр аркасында (авыру, отпуск, командировка) булмавы.

5.17. Контроль орган шикаять биргән контрольдә торучы заттан өстәмә мәгълүмат һәм шикаять предметына караган документлар соратып алырга хокуклы. Контрольдә торучы зат күрсәтелгән мәгълүматны һәм документларны гарызнамә җибәргәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау вакыты узу шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат һәм документлар тапшыру турында гарызнамә җибәргәннән алып Контроль орган аларны алганчы туктатыла, ләкин гарызнамә җибәргәннән соң биш эш көненнән дә артык түгел.

Контрольдә торучы заттан шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат һәм документлар алу шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.

5.18. Шикаять биргән контрольдә торучы заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынган оешмалар карамагында булган мәгълүматны һәм документларны соратып алу рөхсәт ителми.

Шикаятьне биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче, үз теләге белән шикаять предметына караган өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

5.19. Кабул ителгән карарның һәм кылынган гамәлнең (гамәл кылмауның) законлылыгын һәм нигезлелеген раслау бурычы Контроль органга йөкләнә.

5.20. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча контроль органы җитәкчесе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерми калдыра;

2) Контроль орган карарын тулысынча яисә өлешчә гамәлдән чыгара;

3) Контроль орган карарын тулысынча гамәлдән чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органының вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип таный һәм асылы буенча, шул исәптән, кирәк булганда, билгеле бер гамәлләрне гамәлгә ашыру турында карар чыгара.

5.21. Кабул ителгән карарның нигезе, аны үтәү вакыты һәм тәртибе булган Контроль орган карары кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында контрольдә торучы затның шәхси кабинетында урнаштырыла.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль орган карары контрольдә торучы затка, дәүләт яисә закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә басма чыганакта җибәрелә.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү критерийлары[17]**

1. Контроль объектларын куркынычның билгеле бер категориясенә кертү куркыныч күрсәткече дәрәҗәсенә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла:

куркыныч күрсәткеченең зурлыгы 6 дан югары булганда, контроль объекты югары дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә керә;

куркыныч күрсәткеченең зурлыгы 4 тән 6 га кадәр - урта дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә;

куркыныч күрсәткеченең зурлыгы 2 дән 3 кә кадәр – җиңелчә дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә;

куркыныч күрсәткеченең зурлыгы 0 дән алып 1 гә кадәр - түбән дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә.

2. Куркыныч күрсәткече түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$К = 2 x V_1 + V_2 + 2 x V_3$, биредә:

К – куркыныч күрсәткече;

$V_1$ - контроль объектын билгеле бер куркыныч категориясенә кертү турында карар (алга таба - эшчәнлекне куркыныч категориясенә кертү турында карар) кабул ителгән елдан алда килүче ике календарь ел эчендә законлы көченә кергән, Контроль орган тарафыннан төзелгән административ хокук бозулар турында беркетмәләр буенча чыгарылган, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4.1 статьясында каралган административ хокук бозу кылган өчен контрольдә торучы затка (аның вазыйфаи затларына) административ җәза билгеләү хакында карарлар саны;

$V_2$ - контроль объектын билгеле бер куркыныч категориясенә кертү турында карар (алга таба - эшчәнлекне куркыныч категориясенә кертү турында карар) кабул ителгән елдан алда килүче ике календарь ел эчендә законлы көченә кергән, Контроль орган тарафыннан төзелгән административ

[17] Контроль объектларын куркынычлар категориясенә кертүнең күрсәтелгән критерийлары үрнәк характерга ия.

хокук бозулар турында беркетмәләр буенча чыгарылган, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.21-7.23 статьяларында, 9.16 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә, 9.17 статьясында каралган административ хокук бозу кылган өчен контрольдә торучы затка (аның вазыйфаи затларына) административ җәза билгеләү хакында карарлар саны;

$V_3$ - контроль объектын билгеле бер куркыныч категориясенә кертү турында карар (алга таба - эшчәнлекне куркыныч категориясенә кертү турында карар) кабул ителгән елдан алда килүче ике календарь ел эчендә законлы көченә кергән, Контроль орган тарафыннан төзелгән административ хокук бозулар турында беркетмәләр буенча чыгарылган, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясындагы 1 өлешендә каралган административ хокук бозу кылган өчен контрольдә торучы затка (аның вазыйфаи затларына) административ җәза билгеләү хакында карарлар саны;

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2021 елның 8 ноябрендәге
80 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге[18]**

1. Контроль органга күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре булган гражданнан яисә оешмадан, күпфатирлы йорттагы биналардан файдаланучылар булган гражданнардан мөрәҗәгать, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан контрольдә торучы затның эшчәнлегендә түбәндәге мәҗбүри таләпләрнең берсеннән генә булса да тайпылу булу турында мәгълүмат керү:

а) күпфатирлы йортта торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү тәртибенә;

б) күпфатирлы йортта биналарны яңадан планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибенә;

в) күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә;

г) күпфатирлы йортларда инвалидлар өчен биналардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә;

д) күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затларның авария-диспетчерлык хезмәтен гамәлгә ашыру өлешендә эшчәнлегенә;

е) йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларын кулланганда һәм карап тотканда куркынычсызлыкны тәэмин итүгә.

Әлеге индикатор булу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә турыдан-туры зарар (зыян) китерү янавын күрсәтә һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә планнан тыш контроль чараны үткәрү өчен нигез булып тора.

2. Контроль органга күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре булган гражданнан яисә оешмадан, күпфатирлы йорттагы биналардан файдаланучылар булган гражданнардан мөрәҗәгать, дәүләт хакимияте

[18] Күрсәтелгән куркынч индикаторлары исемнәре һәм күрсәткечләре, сайлап алынган параметрлар өчен нормаль халәт параметрлары, күрсәткечләре (бәяләү критерийлары), үлчәү берәмлеге үрнәк характерга ия.

органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында мәгълүмат керү, әлеге мөрәҗәгать, мәгълүмат кергәнче бер ел эчендә контрольдә торучы затка Контроль орган тарафыннан шундый ук мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр бирелгән булса, әлеге типлаштырылган индикаторларның 1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдән һәм 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә планнан тыш тикшерү чарасын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрдән тыш.

3. Контроль орган адресына күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре булган гражданнан яисә оешмадан, күпфатирлы йорттагы биналардан файдаланучылар булган гражданнардан мөрәҗәгатьләр, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында мәгълүмат саны алдагы шундый ук чор белән чагыштырганда һәм (яки) алдагы календарь елының шул ук чоры белән чагыштырганда, вакыт берәмлегенә (ай, алты ай, унике ай) ике тапкырга һәм аннан күбрәк арту.

4. Өч ай дәвамында күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре булган граждан яки оешмадан, күпфатирлы йорттагы бинадан файдаланучы гражданнан мәгълүматның (белешмәләрнең), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматның һәм контрольдә торучы зат тарафыннан торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган мәгълүматның туры килмәвенең биштән артык фактын ачыклау.

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2021 елның 8 ноябрендәге
80 номерлы карарына
3 нче кушымта

## Муниципаль торак контроленең төп күрсәткечләре һәм анық максатчан зурлыклары, муниципаль торак контроле өчен индикатив күрсәткечләр[29]

| Күрсәткеч номеры | Күрсәткеч исеме | Исәплә ү форму ласы | Аңлатма (зурлыкның интерпретациясе) | Күрс әткеч нең төп (база) зурл ыгы | Күрсә ткечне халык ара чагыш тыру | Күрсәткечләрнең максатчан зурлыгы | | | Күрсәткечл әр зурлыклары н билгеләү өчен мәгълүмат чыганаклар ы | Үз эченә күрсәткечне алган (булганда) стратегик планлаштыру документлары турында белешмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | узган ел | агымда гы ел | киләсе ел | | |
| | **ТӨП КҮРСӘТКЕЧЛӘР** | | | | | | | | | |
| **1** | **Законда саклана торган кыйммәтләргә зарарны (зыянны) минимальләштерү дәрәҗәсен чагылдыра торган күрсәткечләр, зарар (зыян)китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсе** | | | | | | | | | |
| 1.1. | Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда биналарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә гражданнарга, оешмаларга һәм дәүләткә китерелгән матди зыян, тулаем | Сп*10 0/ ВРП | Сп - күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда биналарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә гражданнарга, оешмаларга һәм дәүләткә законсыз хисапланган түләүне яңадан исәпләү суммалары, млн. сум; ВРП - расланган тулай региональ продукт, млн. сум; Исәпкә | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары: күрсәтмәләр журналы, тикшерүләр реестры, статистик мәгълүматлар | |

[19] Контроль төренең күрсәтелгән төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан зурлыклары, индикатив күрсәткечләр үрнәк характерда була

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | региональ продукттан процентларда | | алуга төгәллеге кимендә 1 йөз (биштән соң ике билге) булган күрсәткеч зурлыгы кабул ителә, төгәллеге 1 йөздән дә ким булган күрсәткечләр нульгә тиңләштерелә. | | | | | | | |
| 1.2. | Гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зарар китергән мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының ачыкланган бозуларның гомуми саныннан өлеше | Кспв*100% / Ксн | Кспв - үз көчләренә кергән суд карарлары белән расланган гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зарар китерүгә китергән ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары саны;<br><br>Ксн - тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очракларының гомуми саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары; «Правосудие» РФ ДАС мәгълүматлары. | |
| | **ИНДИКАТИВ КҮРСӘТКЕЧЛӘР** | | | | | | | | | |
| **2** | **Контроль эшчәнлеге мониторингы, аны анализлау, аны тормышка ашырганда барлыкка килгән проблемаларны ачыклау һәм зарар (зыян) китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсе белән хезмәт, матди һәм финанс ресурслары күләме арасындагы чагыштыруны характерлый торган сәбәпләрне, шулай ук контрольдә торучы затлар эшчәнлегенә рөхсәтсез катнашу дәрәҗәсен билгеләү өчен кулланыла торган күрсәткечләр** | | | | | | | | | |
| | **2.1. Контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлек иткәндә контроль чаралар** | | | | | | | | | |
| 2.1.1. | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында билгеләнгән вакытта үткәрелгән контроль чараларының гомуми санына карата муниципаль торак контроле кысаларында контроль чараларның өлеше | Пву*100% / Пок | Пву - муниципаль торак контроле кысаларында билгеләнгән вакытларда үткәрелгән контроль чаралар саны<br><br>Пок - муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән контроль чараларының гомуми саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.1.2. | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру барышында муниципаль торак контроле органы биргән күрсәтмәләрнең гомуми санына карата суд тәртибендә законсыз дип танылган күрсәтмәләрнең өлеше | ПРн*100% / ПРо | ПРн - суд тәртибендә законсыз дип табылган күрсәтмәләр саны;<br><br>ПРо - муниципаль торак контроле барышында бирелгән күрсәтмәләрнең гомуми саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |
| 2.1.3. | Муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән, нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган контроль чараларның өлеше | Ппн*100% / Пок | Ппн - нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган контроль чаралар саны;<br>Пок - муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән тикшерү чараларының гомуми саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |
| 2.1.4. | Муниципаль торак контроле органы тарафыннан, аларны үткәрү тәртибе турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып, үткәрелгән, аларны ачыклау нәтиҗәләре буенча мондый контроль чараларны гамәлгә ашыручы муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларына карата дисциплинар, административ җәза чаралары күрелгән контроль чараларның өлеше | Псн*100% /Пок | Псн – муниципаль торак контроле кысаларында аларны үткәрү тәртибе турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып, үткәрелгән, аларны ачыклау нәтиҗәләре буенча мондый контроль чараларны гамәлгә ашыручы муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларына карата дисциплинар, административ җәза чаралары күрелгән контроль чаралар саны<br><br>Пок - муниципаль торак контроле кысаларында үткәрелгән контроль чараларының гомуми саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |
| | **2.2. Контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлексез контроль буенча чаралар** | | | | | | | | | |
| 2.2.1. | Контроль чараларның гомуми саны | инспекциянең статистик | Муниципаль торак контроле органының статистик мәгълүматлары | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мәгълүматлары | | | | | | | | |
| 2.2.2. | Контроль чаралар нәтиҗәләре буенча муниципаль торак контроле органы тарафыннан бирелгән күрсәтмәләрнең гомуми санына карата суд тәртибендә законсыз дип танылган күрсәтмәләрнең өлеше | ПРМБВн*100% / ПРМБВо | ПРМБВн - контроль чаралар нәтиҗәләре буенча муниципаль торак контроле органы тарафыннан бирелгән суд тәртибендә законсыз дип танылган күрсәтмәләр саны<br><br>ПРМБВо - контроль чаралар нәтиҗәләре буенча бирелгән күрсәтмәләр саны | | | | | | Контроль органның статистик мәгълүматлары | |